РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
ЭНТУГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНТУГАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«07» май 2025 ел № 97-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 23 октябрендәге 73-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 23 октябрендәге 73-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 27 маендагы 82-3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 23 октябрендәге 73-1номерлы карарына (02.03.2020 № 79-2, 16.11.2020 №5-2, 30.12.2022. № 61-1 карарлары ред.)

2.1. 2 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,1% , әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш;»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык

һәм яшелчәчелек кертү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган, гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре, җир кишәрлекләренә карата 0,1%, әлеге абзацта күрсәтелгән кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләреннән тыш»;

3, 4, 5, 6 пунктта «кадастр бәясеннән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2. 4 статьяда :

2.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2.3. 5 статьяны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салымны оешма-салым түләүчеләр узган салым чорыннан соң килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча түләргә тиеш. Салым буенча аванс түләүләре салым түләүче-оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килә торган айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш.

Салымны салым түләүчеләр - физик затлар узган салым чорыннан соң килә торган елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләргә тиеш.

Элек исәпләнгән салым суммасын яңадан исәпләү нәтиҗәләре буенча исәпләнгән салым салым түләүчеләр - физик затлар тарафыннан әлеге яңадан исәпләүгә бәйле рәвештә салым хәбәрнамәсе төзелгән айдан соң килә торган өченче айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш.»;

2.4. 7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

2.5. 8 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пунктны өстәргә:

«3. Әлеге карарның 4 статьясындагы 1 пункты 1.4 пунктчасы нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2023-2024 елгы салым чорлары өчен җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла».

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http//buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш һәм 27.05.2024 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе, Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районының Янтуган
авыл җирлеге башлыгы Р.А. Җамалтдинов